## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлеге Коры Көрнәле авыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**2022 елның 12 октябреннән** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 12 октябрендә узган гражданнар җыенының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде, түбәндәге сорау буенча «Сез 2023 елда Алексеевск муниципаль районының «Көрнәле авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге территориясендәге Коры Көрнәле авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан,көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына срокны хезмәткә алынучы гражданнардан тыш.

Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- кышкы һәм җәйге чорда юлларны карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- торак пунктта урамнарны яктыртуны карап тоту (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- торак пункт юлларын төзекләндерү (юлларга таш җәю,килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- күмү урыннарын карап тоту һәм төзекләндерү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- суэтем манарасы өчен су насосын алу;
- янгын гидрантын яңадан урнаштыру.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 188 кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 112 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«ЯКЛЫЙМ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 112 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлегендәге Коры Көрнәле авыл торак пунктында гражданнар җыены булып узды дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Сорау буенча карарны танырга: «Сез 2023 елда Алексеевск муниципаль районының «Көрнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Коры Көрнәле авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына срокл ы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш.

Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- кышкы һәм җәйге чорда юлларны карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- торак пунктта урамнарны яктыртуны карап тоту (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- торак пункт юлларын төзекләндерү (юлларга таш җәю,килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- күмү урыннарын карап тоту һәм төзекләндерү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- суэтем манарасы өчен су насосын алу;
- янгын гидрантын яңадан урнаштыру.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Көрнәле авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Көрнәле авыл җирлеге башлыгы Казакова Д.Б.